**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлегенең Урта Ушма поселогында**
**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2 декабрь, 2019 ел № 8

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә Балтач муниципаль районы Урта Ушма авыл җирлегендә гражданнар җыены карар итте:

1. Балтач районы Кече Лызи авыл җирлегенең урта Ушма авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы һәм тыл ветераннарыннан, ялгыз карт гражданнардан, балигъ булмаган балалар тәрбияләүче тулы булмаган гаиләләрдән, көндезге уку формасында укучы студентлардан кала, 2020 елда 350 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- Ушминка елгасы аша җәяүлеләр күперен ремонтлау.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә baltasi.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru).

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Башлык, Совет рәисе Кече Лызи авыл җирлеге
Балтач муниципаль районы С. А. Мухин